*Мотыгуллина М.И.,*
*ТР Кукмара районы Туембаш авылы төп гомуми белем бирү мәктәбе башлангыч сыйныф укытучысы*

# *Халыкның фольклор традицияләре нигезендә яшь буынга тәрбия һәм белем бирү*

Бездә хәзерге заманда хәл ителәсе, бәхәсле мәсьәләләр гаять күп. Бу мәсьәләләр арасында яшь буынны тәрбияләү, аңар халкыбызга лаеклы тәрбия бирү аеруча кирәкле мәсьәлә. Киләчәгебез, алдагы көнебез, халкыбызның язмышы яшьләрнең бүгенге тәрбиясе белән тыгыз бәйләнгән. Чыннан да урамнарда һәм җәмәгать урыннарында үсмерләрнең, яшьләрнең үзара мөнәсәбәтләренә игътибар итсәң, гаҗәпкә калмыйча мөмкин түгел. Бер-берсенә дорфалык, тупаслык, шәфкатьсезлек, рәхимсезлек. Нинди генә яманлык юк анда! Моны ничек төзәтергә?

XXI гасыр фән-техника чорының югары баскычы. Тормыш шартлары үзгәрде: хезмәт ияләре яхшы йортларда яши, өйдәге аудио, видео – аппаратура, компьютер техникасы, интернет челтәре, кәрәзле телефоннар балаларны бер-берсе белән, өлкәннәр белән аралашудан аерып куйды. Ләкин балаларның үз табигатьләре буенча, без, актив булуларына таянып, аларны татар халкының фольклорына тартырга тиешбез. Безнең хәзерге тәрбиянең төп кимчелеге – тәрбиянең сүзгә корылуында, ягъни тәрбияне сүз(теория) белән аңлатып чикләүдә. Димәк, гаиләдә дә, мәктәптә дә балаларга үз-үзләрен тоту күнекмәләре үзләштерүгә, әхлакый гадәтләр тәрбияләүгә гамәли игътибар кирәк.

Балалык чоры – үзе бер кабатланмас, тылсымлы дөнья. Үзенчә матур, үзенчә серле бу дөньяда тормышыбыз дәвамчылары – яңа шәхесләр тернәкләнә. Шытып чыккан яшь үсенте сыман, нәниләребезгә дә якты кояш, “игелекле туфрак” кирәк. Нәниләр өчен бу, мөгаен, халкыбызның гасырлардан килгән зирәк акыллы, моңлы күңелле, җор теле тудырган иҗат җәүһәрләредер. Шушы олы хәзинәнең бер өлешен без “балалар фольклоры” дип йөртәбез. Балалар фольклоры бала туганнан алып балигъ булганчы аңа өлкәннәр тарафыннан бирелә торган һәм шулай ук балаларның үз мохитләрендә яшәп килгән халык иҗаты әсәрләрен үз эченә ала. Үземнең эш практикамда мин “Балалар фольклоры” китабын өстәл китабы итеп файдаланам. Әлеге җыентыкны дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда куллану уңай нәтиҗәләр бирә.Үземнең эшемдә дә укучыларга тәрбия һәм белем бирү процессында фольклор әсәрләренең бик актуаль булуын яктыртырга телим.

Балалар фольклоры, фунцияләре һәм поэтик үзенчәлекләре ягыннан күптөрле жанрларны эченә ала. Беришләре, мәсәлән, кечкенә балаларны йоклату яки күңелен күтәрү өчен, өлкәннәр тарафыннан башкарыла. Икенчеләрен, хәрәкәтле уеннар белән бәйле рәвештә, балалар үзләре башкара, өченчеләре исә, балаларның күңел ачулары, җорлану вакытында сүз уеннары буларак кулланышка керә. Шуны искә алып, балалар фольклоры

жанрларын “Багу поэзиясе”, “Күңел ачу фольклоры”, “Уен фольклоры” дигән төркемнәргә бүлеп өйрәнү гамәлгә кергән.

Баланы йоклату, күңелен күтәрү максатыннан бишек җырлары баланы бишектә тирбәтеп йоклатканда көйләнә. Салмак көйнең кеше күңеленә тынычландыргыч тәэсир итүен медицина галимнәре, психологлар да таный. Музыканың мондый сыйфатын борынгы әби-бабаларыбыз да белгзннәр һәм баланы тынычландыру, йокыга талдыру чарасы итеп кулланганнар. Кыскасы, бу җырларны борынгы заманнарда үк инде халыкның тәрбияви-гамәли тәҗрибәсе тудырган.

Кеше тормышында бишек җырларының урыны дәрәҗәле. Һәркем аны сабый чакның якты истәлеге итеп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр күңел түрендә саклый. Ул җырлар газиз ана, туган тел, туган ил кебек изге төшенчәләр белән бергә йөри. Бу табигый да, чөнки бала шигъри матурлык, аналарның йөрәк җылысы, үз халкының рухы белән тәүге кат шушы бишек җырларында очраша.

Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү генә калган вакытта башкарыла. Ана ул мәлдә күңеле белән баланың рухи дөньясына якынаерга, уй-фикерләрен нәниләр кабул итәрлек гади, самими итеп әйтергә омтыла. Бишек җырларында аналарның теләкләре, ышанычлары, баласын рухи һәм физик яктан матур, булдыклы, игелекле, мәрхәмәтле гади итеп күрү өметләре чагыла. Аналарның бәгырьдән, йөрәк түреннән чыккан, ягымлы сүзләр белән ана телендә яңгыраган бишек җырлары тәрбиядә башка бернинди чара белән чагыштырырлык һәм алмаштырырлык түгел. Бала әнисен тыңлап, аңа кушылып җырларга, үсә төшкәч, җыр сүзләрен кабатларга тели. Шулай итеп, бишек җырлары аша, сабый туган телендә сүзләрне әйтергә, тирә-якны танып белергә, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерергә өйрәнә, үзе дә сүзләрне әйтергә омтыла.

Бишек җырлары белем һәм тәрбия бирүдә аеруча зур әһәмияткә ия. Әлеге әсәрләрдән дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда еш файдаланабыз. Башлангыч сыйныфларда уку дәресләрендә бишек җырларына аерым игътибар бирелә. Мәсәлән, без укучылар белән “Бишек җырлары” темасын үткәндә, балаларның үзләре яраткан курчакларын бишек җырларын җырлап “йоклатабыз”. Кыз балалар өйдә курчак белән “бала караучы” булып уйнаганда да алардан еш файдаланалар. Музыка дәресләрендә дә бишек җырларын бик яратып башкарабыз. Аларның гаҗәеп бер үзенчәлеге бар: алар, артык вәгазь укымыйча гына, баланы ничек яшәргә, кешеләргә ихтирамлы, мәрхәмәтле булырга, ата-ананы, туганнарны хөрмәт итәргә һәм башка күркәм сыйфат-ларга ия булырга өйрәтәләр. Менә ананың сабыена тели торган шул сүзләре:

Имәндәй нык бул,
Чыршыдай биек бул,
Каендай ак бул,
Чишмәдәй саф бул.

Күренгәнчә, әлеге бишек җырларының беренче юлларында ук ана үзенең баласының сәламәт, әхлакый саф булып үсүен тели. Аннары ул җырны болай дәвам итә:

Ата-аналы бул,
Алтын канатлы бул,
Бай дәүләтле бул.

Тормыш итү өчен кирәкле әйберләр булдырып, кайгы-хәсрәт күрмичә, әти-әниең белән бергә яшәргә язсын. Бу юлларның төп мәгънәсе шунда.

Бишек җырларының алдагы юлларында ана баласында туган телне, халык иҗатын ихтирам итү, табигатькә сакчыл карау хисе тәрбияли:

Бүләк итәм, балам, туган телеңне...
Күңелемә туган олы хисләрне,
Чылтыр чишмәне, алсу иртәне,
Әкият тулы айлы кичләрне...

Бишек җырларын җырлап бала йоклату әти-әниләр белән үткәрелгән кичәләрдә дә зур урын алып тора. Мәсәлән, командаларга “бәби”не тизрәк төреп, бишек җыры җырлап йоклатырга дигән бирем бирелә. Шул рәвешле бишек җырлары бишектәге баланы тәрбияләү өчен иң мөһим чара. Шуларны истә тотып, без, әти-әниләр, мөгаллимнәр балаларда бишек җырларына мәхәббәт тәрбияләргә тиешбез.

Халык иҗатында тәрбиянең һәр юнәлешенә караган, кешедәге барлык әхлакый сыйфатлар хакында фикерләп, тәкъдимнәр, әйтемнәр, киңәшләр, үгет-нәсихәтләр бар. Аларда халыкның балаларга әхлак, акыл тәрбиясе, эстетик, физик тәрбия, белем-сабак бирүгә караганнары аеруча эчтәлекле һәм мәгънәле. Шулардан мәкальләр һәм әйтемнәр зур урын алып тора. Халкыбыз мәкальләрен өйрәнүчеләр: фольклорчылар, тел белгечләре мәкальләрнең грамматик төзелешен, сүзләрнең тапкырлыгын, аларның барлыкка килү тарихын, нинди сабак бирүләрен, мәкальләрнең чыганакларын өйрәнәләр. Без исә аларның тәрбияви ягына игътибар итәбез; балаларны, яшьләрне тәрбияләүдә, аларны ничек куллану мөмкинлекләрен тикшерәбез.

Сөйләшкәндә сүзгә ямь, куәт бирү өчен, көнкүрештә күп сыналган тәҗрибә, дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган кыска, ләкин гомуми бер тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәре мәкаль дип әйтелә. Мәкальнең көчен һәм аның тормышта нинди вазифа үтәгәнен укыганда гына белеп бетереп булмый. Аның яме һәм куәте сөйләшкәндә, сүзне үз урынында әйтеп җибәргән чагында гына тапкыр чагыла. Мәкальне урыны килгәндә генә сүзгә кыстыра белергә кирәк. Югыйсә урынсыз әйтелгән мәкаль вакытсыз кычкырган әтәч шикелле.

Мәкальләрдә төрле дәверләрдәге иҗтимагый-сәяси һәм икътисади мөнәсәбәтләр белән бергә, гаилә тормышы, халыкның әдәп-әхлагы, педагогик карашлары да киң чагыла. Әлеге авыз иҗаты әсәрләре арасында базар, алыш-биреш мәсьәләләренә кагылышлылары да байтак. Бу Болгар дәүләтендә авыл хуҗалыгы һәм һөнәрчелекнең алга киткән булуы белән аңлатыла. Мәсәлән: “Базар барда малың сат, бәхетеңә күрә табыш тап”, “Базарга барып, бәхетеңне сына” һ.б. Ватанны ярату мәкальләрдә кеше

күңелендәге иң изге, иң олы, иң нечкә хис итеп бирелә: “Илнең төтене дә хуш исле”, “Алтын-көмеш яуган җирдән туган ил артык”, “Илен белмәгән – игелексез” һ.б. Еш кына мәкальләр әдәп-әхлак кагыйдәләре төсен алалар, тормыш девизы ролен үтиләр. Алар кыска, аз сүзле, тирән мәгънәле, үгет-нәсыйхәтле. Мәсәлән: “Белем – нур, белмәү – хур”, “Икми иген шытмас, өйрәнми белем йокмас” һ.б.

Мәкаль шикелле, әйтем дә сөйләмне сәнгатьчә бизи, аның эмоциональ көчен арттыра. Ләкин алар арасында аерымлыклар да бар. Әйтемнең мәкальдә булган дидактик гомумиләштерү, хөкем-нәтиҗә ясау сыйфаты юк. Әйтемнәр күчерелмә мәгънәдә генә кулланыла. Ул әйбер яки күренешнең бер сыйфатын образлы итеп ачып бирә.”Тавык йөрәк”, “Кәкре кул” шундыйлардан. Шулай итеп, әйтемнәр дә әйләнә-тирәне танып белергә булыша, акылны үстерә, зиһенне активлаштыра. Әйтемнәр балаларны тәрбияләүнең ата-ана өчен зур җаваплы эш икәнлеген раслый.

Мәкаль, әйтемнәрнең эчтәлекләре бик гыйбрәтле. Аларны өйрәнгәндә, балаларның мәкальләрне яттан белүләре генә җитми. Үсмерләрнең үз-үзләрен тотуда гына түгел, кешеләр белән аралашканда да мәкальләрдә әйтелгән үрнәккә омтылышлары, гыйбрәт алулары аеруча мөһим.

Мин үземнең дәресләремдә халык авыз иҗаты әсәрләреннән мәкаль, әйтемнәрне еш кулланам. Укучыларга мәкаль һәм әйтем турында төшенчә бирүне аваз һәм хәреф белән таныштыру чорында ук башлыйм. Мәсәлән, [д] авазы белән танышканда, түбәндәге мәкаль, әйтемнәрдән файдаланам:

- Дусың булмаса – эзлә,
Тапсаң – югалтма.
- Дус акчадан кыйммәт.
- Дөресен сөйләгән котылыр,
Ялган сөйләгән тотылыр.
- Дөнья яктыра көн белән,
Адәм яктыра белем белән.
- Дөя дә бүләк,
Төймә дә бүләк.
- Данның төбе – хөрмәт,
Хөрмәтнең төбе – хезмәт.

[к] авазын өйрәнгәндә түбәндәге мәкаль, әйтемнәрне кулланабыз:
- Киңәшле эш таркалмас.
-Кадерләсәң кешене, кадерләрләр үзеңне.
-Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.
-Китап – белем чишмәсе.
-Кунак булсаң, тыйнак бул.

[ж] авазына караган мәкаль һәм әйтемнәр:
- Җәй эшләсәң, кыш ашарсың.
- Җаның тынса, кулың тынмый,
Кулың тынса, җаның тынмый.
- Җиде кат үлчә, бер кат кис.

- Җитезгә йөз өлеш,

Җебегәнгә бер өлеш.

Шулай итеп, әлеге мәкаль һәм әйтемнәрне куллану балаларга татар халык иҗатына мәхәббәт тәрбияләргә, укучыларның фикерләү дәрәҗәләрен, сөйләм телләрен үстерергә ярдәм итә. Уку дәресләрендә дә укылган шигырь яки әсәргә карата мәкаль, әйтемнәрне еш кулланабыз. Мәсәлән, Ә Еникинең “Ипекәй” хикәясен укыгач, “Икмәксез алтын тавы башында да үлүең бар”, “Ипекәйне кадерсезләмә, үзең кадерсезлеккә төшәрсең”; Э.Мөэминованың “Яшәү чыганагы” шигырен укыгач, “Агач җимеше белән, адәм эше белән”, “Ни чәчсәң шуны урырсың”, “Киңәшле эш таркалмас”, “Калган эшкә кар явар”, “Зур ихтыяр җир селкетер” кебек мәкальләрне кулланабыз, аларның мәгънәләре турында фикер алышабыз.

Шулай ук хезмәт, табигать белеме дәресләрендә дә алар читтә калмыйлар. Мәсәлән, хезмәт дәресләрендә түбәндәге мәкальләрне куллану уңышлы:

Һәр эшне үз вакытында бетер.

Калган эшкә кар явар.

Ике кулыңа бер эш, иртә тор да кереш.

Хатын-кых эшен тавык та чүпләп бетермәгән.

Эш яратсаң, ул да сине яратыр.

Эш белгән эшләр, белмәгән беләгеn тешләр.

Бүгенге эшне иртәгә калдырма.

Әйләнә-тирә дөнья белән танышу дәресләрендә түбәндәге мәкальләрне кулланабыз:

Тимер таштан табыла.

Күк тимер булат булмас.

Тимер тапкан тилмермәс.

Дәрья төбендәге энҗедән тау башындагы таш артык.

Мәрмәр тапкан тилмермәс.

Асыл таш зур булмас.

Ашлаган җир аш бирә,

Ашламаган таш бирә.

Мәкаль һәм әйтемнәрне татар теле дәресләрендә куллану да кулай. 1 сыйныфта алар матур язу күнегүе өчен файдалы. 2 – 4 классларда “Исем” темасын үткәч, балаларның белем һәм күнекмәләрен ныгыту өчен тактага язылган яки компьютер экранында күренгән түбәндәге мәкальләрне алырга мөмкин:

Кеше күрке – йөз,

Йөзнең күрке – күз,

Уйның күрке – тел,

Телнең күрке – сүз.

Мәкальләр укытыла, мәкальдәге исемнәрнең килешләре билгеләтелә.

Кодоскоп аша экранга төшерелгән түбәндәге мәкальләрдәге исемнәргә кушымчалар өстәп, күчереп язу күнегүләрен дә еш кулланабыз:

1. Акыллы... теле күңелен ...

Тиле... акылы телен...

2. Телең... тыйсаң, тыныч булырсың.
3. Улның ояты ата..., кызның ояты ана...
4. Ана күңеле бала..., бала күңеле дала...
5. Анаң өчен уч төбендә борчак куырсаң да, бурычың... кайтара алмассың.

Мәкаль һәм әйтемнәрне дәрестә төрле уеннар, кроссвордлар рәвешендә дә тәкъдим итәргә була:



Тырышлык – зурлык,
Ялкаулык – хурлык.

Киләчәк заман хикәя фигыльләрне үткәч, түбәндәге кроссворд тәкъдим итәргә була:



Туры әйткән котылыр,
Ялганлаган тотылыр.

Укучылар мәкаль һәм әйтемнәрне үзләре дә эзләп табалар, дәфтәрләренә туплыйлар. Нәтиҗәдә алар әби-бабалары, әти-әниләре белән киңәшәләр, аралашалар. Кыскасы бу эшкә киң җәмәгатьчелек җәлеп ителә.

Татар теле, уку дәресләрендә дәреснең башын ярыш формасында башлыйм. Бер дәрестә “Кем күбрәк белә?” дип мәкаль һәм әйтемнәр әйтеп җиңүчене белсәк, икенче дәрестә “Дәвамын беләсеңме?” дигән ярышта укучы мәкальне дәвам итәргә тиеш. Һәр дәрескә аерым тәрбия темасын алырга тырышам. Мәсәлән:

1. Тел турында:

- Иле барның....(теле бар).
- Зәһәр тел...(йөрәкне яралый).
- Кул ярасы бетәр, ...(тел ярасы бетмәс).

2. Әхлак турында:

- Исәннәрнең кадерен бел, ...(үлгәннәрнең каберен бел).
- Гайбәт сүзне сөйләмә,    (сөйләгәнне тыңлама).

Балалар болай эшләгәндә, мәкальләрне, әйтемнәрне яратып отып алалар. Иң әһәмиятлесе шул: укучыларым үзләренең сөйләмнәрендә мәкаль һәм әйтемнәрне кулланып сөйләшергә яраталар.

Камил акыл, әдәп-әхлак тәрбияләүдә табышмакларның да роле зур. Табышмакка җавап табу өчен, ут кебек зиһен йөгереклелеге кирәк. Ул үзе кечкенә булса да, эче төш кенә. Аның шул төшен табу кызыклы. Тик моның өчен хыялың бай һәм җитез булсын да зиһенең йөгерек булсын. Табышмакларны иҗат итеп, халык камил акыл, әдәп-әхлак тәрбияләүне күз алдында тоткан. Табышмаклар аеруча балаларда зирәклек, тапкырлык, логик фикерләү сәләтен үстерә, сөйләмне камилләштерә. Алар балалар өчен эстетик ләззәт чыганагы.

Дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда халык педагогикасының бай хәзинәләреннән, табышмаклардан файдалану уңай нәтиҗәләр бирә. Мәсәлән, балаларны уйларга, санарга өйрәтүдә түбәндәге мәсьәлә табышмакларны кулланырга була:

“Көтүлектә”. Ике малай сарыклар көтәләр. Әгәр беренчесе икенчесенә бер сарык бирсә, икесенең дә сарыклар саны тигез була. Әгәр икенчесе беренчесенә бер сарык бирсә, беренчесенең сарыклары икенчесенекенә караганда ике тапкыр артык була. Беренче һәм икенче көтүченең ничә сарыгы булган?

Җавап: беренче көтүченең – 7, икенче көтүченең – 5 сарыгы булган.

Балаларга белем бирү процессында микъдар санын күзаллауны һәм ел, ай, атна, көн турындагы белемнәрне үзләштерү; аны үстерү өчен дә математик табышмакларны киң кулланабыз:

1. Унике йолдыз, бер ай.
2. Бер өянкәдә унике ботак.
3. Һәр яфракның бер ягы кара, бер ягы ак.
4. Бер тирәк, унике ботак
   Һәр ботакта дүрт чыпчык
   Һәр чыпчыкта җиде яфрак
   Һәр яфракның бер ягы кара, бер ягы ак.
5. Өч йөз алтмыш биш сыерчык
   Илле ике тубырчык;
   Унике аккош, бер торна, аны белми күп торма.

Табышмакларны барлык төр дәресләрдә дә куллану бик отышлы. Без аларны хезмәт дәресләрендә дә киң кулланабыз:

Күзе бар, авызы юк,
Койрыгы бар, йоны юк (энә).
Койрыгыннан күтәреп булмый (йомгак).
Ике бөҗра, ике таяк,
Уртасында бер кадак (кайчы).
Әбием күзенә бармагым кереп китте (уймак).
Ай киттем, ел киттем,
Энә буе җир киттем (тегү).
Тек-тек итәр, текмәштән китәр ( тегү машинасы).

Агасы турый, энесе ялгый (кайчы һәм энә).

Башында миңе булмаса да, кешегә кирәк (булавка, кадавыч).

Табигать һәм көнкүреш турындагы табышмаклар да бик күп. Аларны без әйләнә-тирә дөнья белән танышу дәресләрендә кулланабыз:

Урманда урынсыз,
Кырда койрыксыз (җил).
Өй башында ярты ипи (ай).
Кара мыеклы җизнәм
Сагындырып килгән (яз).
Төн әйләнә кара икмәк,
Эче тулы алтын кибәк (күк һәм йолдызлар).
Борынсыз чыпчык боз тишә (тамчы).
Күктән килде, җиргә китте (яңгыр).
Ак ашъяулык таптык,
Җир өстенә яптык (кар).

1 сыйныфта аваз һәм хәреф белән таныштыру чорында ук табышмакларга зур урын бирелә. Мәсәлән, [у] авазын өйрәнгәндә,

Озын идем – киселдем,
Юан идем – ярылдым,
Инде утка тарыдым (утын);
[к] авазы белән танышканда,
Эче кызыл, тышы яшел,
Аны сатып алалар,
Аны күргән балалар
Ымсынышып калалар ( карбыз).

Табышмакларны кроссвордлар рәвешендә дә тәкъдим итәргә була:



Авырлыгым ташка,
Җиңеллегем үземә.
Су анасы, сукранма,
Миңа саулык,
Сиңа ... (яулык).
Ике агай тездән,
Калышмыйлар бездән (итек).
Йомшак, йөнтәс этемнең
Озындыр колаклары.
Җылы булса, күтәрә,
Суык булса, төшерә (бүрек).

Бер тишектән керәмең,
Өч тишектән чыгасың (күлмәк).
Тышы урман, эче кыр,
Ул суыктан саклыйдыр (тун).
Кара тавык, карыны ярык (кәвеш).

Шулай итеп, фольклор әсәрләре, белем тәҗрибәсе күп гасырлар буе буыннан-буынга күчеп килеп, яшь буынга тапшырыла бара. Тәрбия һәм төпле белем алу, нигездә, мәктәптән башлана. Дәресләрдә фольклор әсәрләреннән мәкаль, әйтем, табышмак, җыр, уен, әкиятләрне куллану зур әһәмияткә ия.

Фольклор әсәрләрен бүгенге укыту – тәрбия эшенә кертүне түбәндәге юнәлешләрдә алып барырга кирәк:

1. Балаларны оста, халыкчан тәрбияләүче ата-аналарның тәҗрибәсен җентекләп өйрәнү, туплау, барлык ата-аналарга җиткерү.
2. Фольклор әсәрләрен укытучылар әзерли торган һәр уку йортында махсус фән итеп өйрәнергә кирәк. Булачак укытучылар халыкчан тәрбиянең эчтәлеген өйрәнеп, үз эшләрендә кулланыпга тырышсыннар иде.
3. Балалар фольклоры әсәрләрен иң элек гаиләдә, балалар бакчасында даими куллану кирәк. Мәктәпләрдә барлык фәннәр буенча үткәрелә торган дәресләрдә дә әлеге әсәрләрдән кулланырга мөмкин. Дәрестән тыш эшләр үткәргәндә дә халык җәүһәрләрен куллану тәрбия эшенең тәэсирлеген, уңай нәтиҗәлелеген сизелерлек яктырта. Балалар да бу чараларда теләп йөриләр.
4. Халкыбыз галимнәренең, әдипләренең укыту – тәрбиягә карашы өйрәнелә башлады. Мәсәлән, Г. Тукай, К. Насыйри, Г. Ибраһимов һәм башкаларның педагогик карашлары турында хәзер инде беләбез. Ләкин халкыбызның алтын хәзинәсен – яшь буынны укыту – тәрбияләү турындагы белем һәм тәҗрибәне бүген тирәнтен өйрәнү һәм гамәлдә куллану максаты белән фәнни тикшеренүләрне, методик эзләнүләрне нык көчәйтү сорала. Халыкчан булганда гына укыту – тәрбия көчле тәэсирле һәм уңай нәтиҗәле була.

## Әдәбият


1. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен / Төз. Н. Исәнбәт. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1984 ел.
2. Габдрахманов Н. Халык традицияләре җирлегендә. – Мәгариф. - 1998. - №1.
3. Галимов Ф. Халык җырлары – олы мирасыбыз. – Мәгариф. - 2000. - №3.
4. Исәнбәт Н. Отканга мәкаль, тапкырга табышмак. - Казан: Татар китап нәшрияты, 1973.
5. Исхакова М. Дәрестә халык авыз иҗаты. - Мәгариф. - 1999. - №2.
6. Кәҗә-мәкәрҗә / Төз. Р. Ягъфәров. – Казан: Мәгариф, 1994.
7. Мостафин Ф. Халык әхлаклылык тәрбияли. - Мәгариф. - 1992. - №6.

8. Нигъмәтҗанов М.Н. Татар халык җырлары. - Казан: Татар китап нәшрияты, 1976.
9. Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1980.
10. Татар халык иҗаты: Мәкаль һәм әйтемнәр. - Казан: Татар китап нәшрияты, 1987.
11. Халык уеннары. - Казан: Татар китап нәшрияты, 1990.